ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**31.01.2023**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№152**

Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәрендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законына, 1996 елның 12 январендәне «Җирләү һәм җирләү эше турында» 8-ФЗ санлы Федераль законына, 2007 елның 18 маендагы «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 30 гыйнварындагы «2023 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» 119 номерлы карарына туры китереп, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск шәһәрендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 2023 елның 1 февраленнән, 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымтада каралганча, 7 793,48 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. 2023 елның 1 февраленнән «Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәрендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 31 гыйнварындагы 177 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru )урнаштырырга .

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның 31 гыйнварындагы
152 номеры карарына
1 нче кушымта

2023 елның 01 февраленнән Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәрендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәяләре

| Хезмәтләр атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда )* |
|---|---|
| 1. Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Мәетне җирләү өчен табут һәм башка кирәкле әйберләрне тәкъдим итү һәм китереп бирү | 4 247,07 |
| 3. Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәден) алып бару | 1 209,84 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм җирләү) | 2 336,57 |
| **Барлыгы** | **7 793,48** |

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның 31 гыйнварындагы
152 номеры карарына
2 нче кушымта

2023 елның 01 февраленнән Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәрендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәяләре

| **Хезмәтләр атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда )*** |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Гыйбәдәт киеме кидертү/ Кәфенләү | 750,35 |
| 3. Мәетне җирләү өчен табут һәм башка кирәкле әйберләрне тәкъдим итү һәм китереп бирү | 3 496,72 |
| 4. Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәден) алып бару | 1 209,84 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм җирләү) | 2 336,57 |
| **Барлыгы** | **7 793,48** |